СОВЕТ ВОЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.05.2024 г. с. Войкино № 68

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә,

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Советы карар бирде**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына:

Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан бюджет законнары нигезендә Войкино авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Войкино авыл җирлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлекнең рәсми сайтында, «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» рәсми рәвештә халыкка җиткерергә;

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы Войкино**
**авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Н.П.Шабутдинова**